СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.06.2024 г. Заинск № 334

**«Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 13 апрелендәге 280 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

# КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Советының 2018 елның 13 апрелендәге 280 номерлы "Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре булмаган белгечләрнең һәм Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарындагы эшчеләрнең хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турында" гы карары белән расланган Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарындагы белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәгә (Зәй муниципаль районы Советының 27.08.2020 №555, 27.12.2021 №192, 29.09.2022 №235, 18.11.2022 елның 245 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктта "12688 сум" сүзен "13323 сум" сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 2.3 пунктның 3 пунктчасында "15 процент" сүзен "37 процент" сүзләре белән алыштырырга;

1.3. 2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.9. Билгеләнгән түләү фонды чикләрендә эшчеләргә һәм белгечләргә юбилей даталары (50 яшьлек, 55 яшьлек, 60 яшьлек, 65 яшьлек), никахлашу,

бала туу (уллыкка алу, кызлыкка алу), хезмәткәрнең тормыш иптәше, балалары, әти-әнисе үлү һәм башка вакыйгалар белән бәйле рәвештә ун мең сум күләмендә матди ярдәм түләнергә мөмкин.".

2. Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башлыгы урынбасары П.С.Уразайкинга йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**